**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮҢГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422008 Республика Татарстан Атнинский район д.Ниңние Шаши тел.3-60-38


КАРАР

18 ноябрь 2022 ел № 6

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2022 елның 29 ноябренә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Күшәр авылы Татарстан,Х.Такташ,Тукай һәм Сәйдәш урамыннарында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенның беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 29 ноябренә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Күшәр авылы Комсомолҗская,Фрунзе һәм Октябрь урамнарында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенның икенче этабын билгеләргә.

Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенынын беренче этабын үткәрү вакыты – 29 ноябрь 2022 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенынын икенче этабын үткәрү вакыты – 29 ноябрь 2022 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр
- халык җыенының беренче этабын үткәрү урыны – Күшәр авылы, Татарстан урамы, мәдәният йорты каршында;
- халык җыенының икенче этабын үткәрү урыны – Күшәр авылы, Комсомольская урамы, балалар уен мәйданчыгы янәшәсендә;

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Шашы авылы, Яшьләр урамы, 68 нче йорт;
- сайлау хокукына ия булган Күшәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Күшәр торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам утларын яктырту максатыннан лампалар,автоматлар,стартер, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;
- авыл территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу,чистарту),хезмәтләр өчен түләү.
- Комсомольская һәм Х.Такташ урамыннарында урнашкан чишмәләрне койма белән әйләндереп алу (төзелеш материаллары алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү).
- Комсомольская урамындагы чишмәгә төшү юлына басма төзү;
- Комсомольская урамындагы юлга асфальт җәю.

| “РИЗА” | “КАРШЫ” |
|---|---|

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб–адресы, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Шашы авылы, Яшьләр урамы 68 нче йорт адресы буенча Күңгәр авыл җирлеге Башкарма комитеты стендына урнаштырырга.
7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге Советы
5 нче округ депутаты: Абдуллин Р.Х.